СОВЕТ НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«27» июнь 2022 ел № 58

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегендә гавами тыңлауларын (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2021 елның 11 июнендәге 191-ФЗ номерлы "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы Федераль законга туры китереп, прокуратураның 2022 елның 15.апрелендәге 02-08-01-2022 номерлы Норма авыл җирлеге Советының 2020 елның 23 июнендәге 169 номерлы «Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау турында»гы карарына протесты һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышуларын) үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 статьясының 4 пунктындагы икенче абзацында "язма формада" сүзтезмәсеннән соң түбәндәге эчтәлектәге сүзтезмә өстәргә: "яисә җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыручы адресына электрон документ формасында";

1.2. Нигезләмәнең 6 статьясындагы 5 пунктында “язма" сүзеннән соң "яисә электрон документ формасында” сүстезмәсен өстәргә;

1.3. Нигезләмәнең 7 статьясындагы 6 пунктында “язма” сүзеннән соң "яисә электрон документ формасында” сүзтезмәсен өстәргә:

1.4. Нигезләмәнең 8 статьясындагы 2 пунктында “язма формада" сүзтезмәсеннән соң түбәндәге эчтәлектәге сүзтезмә өстәргә: "яисә җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыжлауларны оештыручы адресына электрон документ формасында”;

1.5. Нигезләмәнең 5 нче кушымтасында “язма” сүзеннән соң "яисә электрон документ формасында" сүзтезмәсен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов